РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 28 декабре № 58

# Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарга муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектерү буенча социаль ярдәм чаралары бирү турында

«Өлешчә мобилизацияләүгә бәйле рәвештә федераль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 октябрендәге 3046-р номерлы боерыгы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларга дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектерү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 16 ноябрендәге 2507-р номерлы күрсәтмәсе, Түбән Кама муниципаль районы Уставының 30 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсенә Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, әгәр күрсәтелгән физик затлар, юридик затны гамәлгә куючы (катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган шәхси эшмәкәрләр яки физик затлар Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучы яисә «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты (алга таба – Федераль закон) нигезендә төзелгән контракт буенча махсус хәрби операция барышында хәрби хезмәт узучы, яисә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзүче булган очракта, аларны арендага алучы булып торган физик затлар, шул исәптән юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган бер үк физик зат торган шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затларга түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен түләүне кичектерү (алга таба – аренда түләвен түләүне кичектерү);

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлекләре.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен түләүне кичектерү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат тарафыннан аренда түләвен түләүне кичектерү чорына мөлкәт шартнамәсе буенча арендага алынганны файдаланмау;

арендага алучы, шул исәптән ышанычлы затлар аша, арендага бирүчегә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәт узу

статусын раслаучы документлар күчермәләре яки күрсәтелгән контрактлар төзелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырылган Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә махсус хәрби операция барышында хәрби хезмәт узу турында контракт төзү турында хәбәрнамә күчермәсе яисә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт күчермәсе белән аренда түләвен түләүне кичектерү турында хәбәрнамә җибәрә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән арендага алучыга әлеге карарның 4 пункты нигезендә исәпләнә торган чорга аренда түләвен түләүне кичектерү бирелә;

аренда түләве буенча бурыч аренда шартнамәсенә өстәмә килешү нигезендә аренда түләвен түләүне кичектереп тору чоры тәмамланганнан соң этаплап, айга бер тапкырдан артмаган вакытта, аларның күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган күләмдә тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

арендага түләүне кичектерүгә бәйле рәвештә арендатор түләргә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда башкаларның акчаларыннан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки арендаторның аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәвенә бәйле башка җаваплылык чаралары (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсе белән каралган очракларда) кулланылмый.

3. Аренда шартнамәсен әлеге карарның 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән штраф санкцияләрен кулланмыйча өзү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

арендага алучы, шул исәптән ышанычлы затлар аша, арендага бирүчегә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәт узу статусын раслаучы документлар күчермәләре яки күрсәтелгән контрактлар төзелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырылган Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә махсус хәрби операция барышында хәрби хезмәт узу турында контракт төзү турында хәбәрнамә күчермәсе яисә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт күчермәсе белән аренда түләвен түләүне кичектерү турында хәбәрнамә җибәрә;

аренда шартнамәсе арендага бирүче аренда шартнамәсен өзү турында хәбәрнамә алган көннән юкка чыгарылырга тиеш;

башкаларның акчаларыннан файдаланган өчен процентлар, штрафлар яки аренда шартнамәсе өзелүгә бәйле башка җаваплылык чаралары кулланылмый (шул исәптән аренда шартнамәсендә мондый чаралар каралган очракларда да).

4. Аренда түләвен түләүне кичектерү срогы 90 көнгә арттырылган мобилизация срогы кебек исәпләнә һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затның хастаханәләрдә, госпитальләрдә, башка медицина оешмаларында стационар шартларда мобилизация чорында бурычларны үтәгәндә алынган имгәнүдән (яраланудан, җәрәхәттән, контузиядән) яки авырудан дәвалану чорына озайтыла, ә әлеге күрсәтмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затны хәбәрсез югалган дип тану очрагында – шулай ук судның аны хәбәрсез югалуын тану турында карарны гамәлдән чыгарган яисә суд тарафыннан аның һәлак булган дип игълан ителгән чорга кадәр.

Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затның һәлак булуы (үлеме) очрагында, әгәр ул мобилизация чорында яки күрсәтелгән чордан соң, ләкин мобилизация чорында алынган имгәнү (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яки авыру аркасында һәлак булса (үлсә), шулай ук аны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалид дип таныган очракта, кичектереп тору чорына аренда түләве түләнми, түләттерү өметсез дип танала һәм билгеләнгән тәртиптә чыгымга чыгарылырга тиеш.

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә имгәнүгә (яралануга, җәрәхәтләнүгә, контузиягә) яки үлемгә яисә I төркем инвалид дип танылуга китергән

авыруларның мобилизация чоры белән сәбәпле бәйләнеше хәрби-табиб комиссияләре һәм (яки) федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан билгеләнә.

5. Муниципаль предприятиеләргә һәм муниципаль учреждениеләргә хуҗалык алып бару хокукында яисә муниципаль предприятиеләргә оператив идарә итү хокукында яисә муниципаль учреждениеләргә оператив идарә итү хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, әгәр күрсәтелгән физик затлар, юридик затны гамәлгә куючы (катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган шәхси эшмәкәрләр яки физик затлар Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучы яисә «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты (алга таба – Федераль закон) нигезендә төзелгән контракт буенча махсус хәрби операция барышында хәрби хезмәт узучы, яисә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзүче булган очракта, аларны арендага алучы булып торган физик затлар, шул исәптән юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган бер үк физик зат торган шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затларга түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен түләүне кичектерү;

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлекләре.

6. Әлеге карарның 5 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен түләүне кичектерү әлеге карарның 2 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карарның 5 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда шартнамәсен өзү әлеге карарның 3 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге карарның көче 2022 елның 21 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.Х.Муллин